КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 27

Казан шәһәре, Щапов урамы, 37 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Актриса, җәмәгать эшлеклесе, драматург, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Рәшидә Габдуллаҗан кызы Җиһаншина истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һәм «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең Р.Г.Җиһаншинага Казан шәһәре, Щапов урамы, 37 нче йорт адресы буенча бина фасадына рус һәм татар телләрендәге түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«В 1971 – 1988 годах
Татарстанское отделение
Всероссийского театрального общества
возглавляла
народная артистка РСФСР и ТАССР
Рашида Абдуллазяновна
Зиганшина

___________

1971 – 1988 елларда
Бөтенроссия театр җәмгыятенең
Татарстан бүлеген
РСФСР һәм ТАССРның халык артисткасы
Рәшидә Габдуллаҗан кызы
Җиһаншина җитәкләде».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның балансta тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин